СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

19 МАРТ, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 30 (8042) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Районыбыз тормышыннан хәбәрләр

### АВТОБУСЛАР ЙӨРИ

#### ...Салдакайга

Берара Норлаттан Салдакай авылына маршрут автобусы йөреп алган иде. Олы юлдан читтә урнашкан авыл халкы бик сөенгән иде моңа. Әмма халыкның шатлануы озакка бармады: билгесез сәбәпләр буенча маршрут ябылды. Әмма халык АТП, автовокзал администрациясенә автобус йөртүне сорап йөрүдән туктамады.

Ниһаять, күптән түгел халык үтенече буенча Салдакайга янә автобуслар йөри башлады. Чәршәмбе һәм пәнҗешәмбедә көнгә өчәр рейс ясый анда автобуслар. Халык канәгать: төрле йомышлар белән тиз арада район үзәгенә барып, һичнинди проблемасыз әйләнеп кайту мөмкинлекләре бар бит аларның.

#### ... Базардан—базарга

Үзәк базар икегә - азык - төлек һәм промышленность товарлары базарларына бүленгәч, район җитәкчелеге халыкка җиңеллек тудыру максатыннан ике базар арасында автобуслар йөртүне кулай күрде. Хәзер шимбә һәм якшәмбе көннәрендә ике арада көне буе автобуслар хәрәкәт итә. Аларның берсе АТПныкы булса, икенчесе - райпоныкы.

Киләчәктә автобуслар ял көннәрендә генә түгел, гадәти көннәрдә дә йөрер дип көтелә.

### РУЛЬ АРТЫНДА... АСЫЛ ЗАТЛАР

Элегрәк автомобиль руле артында хатын - кыз утыруын күрсәк, гаҗәпләнә идек. Ә хәзер бу гадәти күренешкә әверелде: асыл затларыбыз автомашиналарны ир - атлардан ким йөртмиләр.

Аңлашыла ки, шофер таныклыгы алу өчен курсларда укучы хатын - кызлар саны да арта бара. Узган чәршәмбедә оборона спорт - техника оешмасы каршындагы һәвәскәр шоферлар хәзерләү курсларында укып, «АВ» категорияле таныклыклар алучы 57 кешенең 13се хатын - кызлар иде. Аннан элекке агымда таныклыклар алучы хатын - кызлар 18әү булган.

## 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

### АЧЫКТАН - АЧЫК СӨЙЛӘШҮ

**14 мартта район мәдәният йортында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның шәһәр сайлаучылары белән очрашуы булды.**

Ул көнне залда буш урыннар юк иде диярлек. Сайлаучыларның район башлыгы, аның сайлау алды платформасы белән якыннан танышасылары, киләчәк перспективалары турында күбрәк беләселәре, бер сүз белән әйткәндә, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавапны аның үз авызыннан ишетәселәре килде. Бу җәһәттән чараның эш планында «ачык хат» көне үткәрү дә планлаштырылган иде.

Очрашуны кереш сүз белән хакимият башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова ачты. Ул сүзне депутатлыкка кандидатның ышанычлысы Л.Н.Газизуллинага бирде. Икенчесе исә Ф.С.Сибагатуллинның хезмәт биографиясе, төрле постларда эшчәнлеге турында сөйләп, яңа җитәкченең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә районда авыл хуҗалыгы производствосындагы беренче чираттагы бурычлар, шулай ук социаль мәсьәләләрнең хәл ителүен ассызыклады.

Аннан соң Фатих Сәүбәнович Сибагатуллин чыгыш ясады.

- Минем бүген шәһәр халкы белән очрашуымның максаты,- диде ул,- сайлаучыларның тәкъдимнәрен ишетү һәм аларны районның нинди төп максатлар өстендә эшләве һәм киләчәккә планнары белән таныштыру. Аерым алганда, ул байтак юнәлешләр буенча гамәли планнар белән бүлеште. Мисал өчен шикәр заводын бүгенгечә 100 көнгә түгел, ә даими эш белән тәэмин итәргә, технологик линияләрне реконструкцияләү, яңартуга якынча 60 миллиард сум акча кертергә кирәк. Шул максатта Россиядәге иң җитди банкларның берсе булган «Инкомбанк» белән сөйләшүләр алып барыла. Өстәвенә, заводның бурычлары да байтак.

Зүзәй нефть промыселының нәтиҗәлелеген күтәрү зарури. Аның базасында куәтле нефть эшкәртү предприятиесе булдыру күздә тотыла. Моның өчен тагын 30 миллиард сум акча таләп ителәчәк. Бүген район хакимияте бу мәсьәлә өстендә эшли. Барлык бу звенолар бер экономик чылбырның буыннары: кертелгән акчалар эшкә «җигелгәч», социаль мәсьәләләрне хәл итү эше дә җиңеләячәк.

Төрнәс спирт заводына да җитди роль бирелә. Анда сыйфатлы эчемлекләр җитештерү күздә тотыла. Мәгълүм булганча, аларны җитештерү иң керемле эшләрнең берсе. Димәк, җирле бюджет та стабиль тулыланачак.

Хакимият башлыгы районга «тере» акча керүнең тагын бер мөмкинлеге турында да искәртте. Сүз хуҗалыкларда югары продуктлы француз терлеген үрчетү турында бара. Беренчедән, югары категорияле ит җитештерү үзе үк табышлы, икенчедән, нәселле терлекне башка регионнарга да сату мөмкинлеге ачылачак. Шул турыда сөйләгәндә, хакимият башлыгы бүгенге көн белән генә яшәп булмаячагын ассызыклады. Яңача фикерләргә өйрәнергә, перспективаны күрә белергә, экономик хәлне яхшыртуның төрле вариантларын эзләргә кирәк. Әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә октябрьлеләрнең үзара аңлашып эшләүләре мөһим.

Районның тулаем социаль - экономик хәлен характерлап Ф.С.Сибагатуллин уңай моментларны билгеләде. Бюджет учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт хакы, пенсионерларга пенсия даими бирелә. Республикада беркайда булмаганча реформалау мәсьәләләре актив хәл ителә - бүген бездә производство мөнәсәбәтләренең 8 төре теркәлгән. Авыл хуҗалыгы ассоциацияләренең бер өлешенең предприятиеләргә ярдәмче хуҗалык итеп бирелүе нәтиҗәсендә, алар терлекчелектә яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр. Мисал өчен, сентябрьдә ассоциацияләр дәүләткә көн саен 28 тонна сөт сатсалар, хәзер инде 75 тонна.

(Ахыры 2 нче биттә).

## Норлат - Зирекле юллары

### ЭХ, РӘХӘТ КАЙТУЛАРЫ!

Тумышыбыз белән бу яклардан булсак та, күптәннән Әлмәт якларында яшибез. Авылда гарип малае белән 70 яшьлек апам яшәгәнлектән, Зиреклегә еш кайтырга туры килә. Элек Норлатка кадәр әйбәт кенә кайтабыз да, Зиреклегә кайтып җитә алмыйча аптырый идек. Соңгы кайтуыбызда да шул юл газабын уйлап, алдан ук борчылып юлга чыккан идек. Әмма юкка борчылганбыз: безне шатлыклы хәбәр көтә - Зиреклегә автобус йөри башлаган икән. Халык белән тулы автобуска утыргач, тыңлап кайтам: яше - карты бер булып бу игелекне эшләгән хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллинга рәхмәт укыйлар. Мин дә сөенә - сөенә сөйләшүгә кушылам: бигрәк игелекле кеше булды яңа җитәкче, кайткан саен бер үзгәреш сездә - әле газ кертелгән, әле юл ачылган, дим. Якташларымның киләчәге дә өметле болай булгач. Яңа автобус маршруты ачып, халыкны юл газабыннан коткарган хакимият башлыгына халыкның олы рәхмәтен җиткерсәгез икән.

**Исхак МӨХӘММӘТОВ.**
**Әлмәт шәһәре.**

## Хезмәтләре белән мактаулылар



Эшлим дигән кеше өчен авылда эшнең һичкайчан бетеп торганы юк. Анатолий өчен дә нәкъ менә шулай: көз КС - 6 комбайны белән чөгендер казытып бетереп, техникасын кышкы саклауга куярга гына өлгерә, фермага эшкә чакыралар. Ә Анатолий Дмитриевич бер генә эшкә дә җавапсыз карый алмый: техникага мөнәсәбәте нинди булса, малларга да шундый ук. Шуңа да иртә таңнан торып фермага юнәлә ул. Дөресрәге, Герасимовлар йортыннан фермага берьюлы ике кеше чыгып китә - хатыны Зоя да товарлыклы - сөтчелек фермасында хезмәт куя. Анатолий маллар карый, Зоя исә сыерлар сава, икесе дә тырышлар. Гаиләдә бер - бер артлы дөньяга килгән биш баланың да, кул арасына кергән берсе фермага әти - әниләренә булышырга йөриләр. Балалары да үзләре үрнәгендә яшьли хезмәт сөючән булып үсәләр.

**Рәсемдә: «Правда» КХАсы терлекчесе А.Герасимов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## ДЕПУТАТ САЙЛАНДЫ

1997 елның 15 мартында 18 нче Егоркино сайлау округыннан халык депутатларының район Советына депутат сайлау булды.

Бу округтан депутат итеп 1950 елгы, Норлат разведка бораулавы идарәсе начальнигы **Анатолий Степанович НАСОЛДИН** сайланды.

Район сайлау комиссиясе белдерүеннән күренгәнчә, тавыш бирү исемлегенә 1138 сайлаучы кертелгән булган. 1018 сайлаучы депутатлыкка кандидатны яклап, 12се каршы тавыш биргән, дөрес түгел дип табылган бюллетеньнәр булмаган.

## САЙЛАУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Район сайлау комиссиясе карары белән һәм «Татарстан Республикасында халык депутатларының җирле Советларына халык депутатларын сайлау турында» Татарстан Республикасы Законының 41 нче маддәсе нигезендә **22 нче Совхоз** сайлау округыннан район Советына депутат сайлау 1997 елның 4 маена билгеләнде.

**Район сайлау комиссиясе.**

## «КОМИССИЯГӘ ЧАКЫРАБЫЗ...»

Күптән түгел юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясенең чираттагы утырышы булды. Анда билгеләп үтелгәнчә, районда юл - транспорт вакыйгалары бераз азая төшсә дә, фаҗигаләр дәрәҗәсе югары булуында кала әле.

Былтыр юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен 10 меңнән күбрәк руль иясе административ җаваплылыкка тартылган, мең кешегә эчкән хәлдә транспорт белән идарә иткән өчен җәза бирелгән, шуларның утыздан күбрәге - урындагы кешеләр. Һәр алтынчы юл - транспорт вакыйгасында исерек транспортчылар гаепле.

Юлларның торышы да тиешле таләпләргә һаман да тулысынча җавап биреп бетерми әле.

Комиссия утырышында кайбер предприятие - оешмалар җитәкчеләренең аларда транспорт дисциплинасының торышы турында информацияләре дә тыңланды.

# 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

## АЧЫКТАН - АЧЫК СӨЙЛӘШҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Сөт саву буенча исә район республикадагы 33 нче урыннан 7нчегә күчте. Әирешелгәннәрне ныгытырга һәм үстерергә кирәк.

Аннан соң ул алкышлар астында «Норлат - Октябрь элеваторы» АҖ генераль директоры Э.Н.Миназовка «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме бирелү турында Татарстан Республикасы Президенты Грамотасын һәм билге тапшырды.

Сонрак Ф.С.Сибагатуллин шәһәрлеләр сорауларына җавап бирде, ә алар арасында пенсионерлар да байтак иде. Ә сораулар берничә дистә - язмача да, телдән дә житкерелде һәм аларның эчтәлеге, нигездә тормыш - көнкүреш мәсьәләләренә бәйле иде. Хакимият башлыгына баллонлы газ белән тәэмин итүдәге өзеклекләр һәм челтәрле газ бирүне тизләтү кирәклеге, телефонлаштырудагы тоткарлыклар, шәһәрдә базар сәүдәсен оештыру эшендәге җитешсезлекләр турында сөйләделәр. Залдагыларны экология, Норлат шәһәрендәге сәүдә үзәге төзелешен тәмамлау, урамнарны кардан чистарту, халыкны утын белән тәэмин итү, читтәге урамнарны төзекләндерү, кадрлар мәсьәләләре борчыды. Шәһәрлеләр үз чыгышларында нинди генә кискен проблемаларга кагылсалар да, һәрвакыт аларның җитәкчелеккә үз сорауларын яхшы ният һәм хөрмәт белән бирүләре сизелеп тора иде: яхшы якка унай үзгәрешләргә битараф калу мөмкин түгел шул. Бу җәһәттән, ветераннарның берсе болай диде: «Район газетасы язмалары аркылы районда эшнең ничек баруын күзәтәбез. Аларның рәтләнүенә шатбыз». Ул фикерне икенчесе дәвам итте: «30 мартта без үз кандидатыбызга тавыш бирәчәкбез. Башкаларны да шуңа чакырабыз».

Ф.С.Сибагатуллин телдән бирелгән барлык сорауларны да игътибар белән тыңлады. Язмачаларына исә шәһәр җирле үзидарәсе Советы рәисе Ф.И.Гайнуллинга биш көнлек срок эчендә җавап бирү йөкләнде.

Шәһәрлеләр тәкъдиме белән шундый очрашуларны даими рәвештә, шул исәптән микрорайоннар буенча үткәрергә, халыкны кызыксындырган сорауларга турыдан - туры район службалары, предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре җавап бирәчәкләр.

Шәһәрлеләр белән очрашу азагында хакимият башлыгы коллективлар вәкилләрен - сәүдә, көнкүреш хезмәте, торак - коммуналь хуҗалыгы хезмәткәрләренең һөнәри бәйрәмнәре белән котлап, МПП ЖКХсы коллективы алдынгыларына «Татжилкомхоз», хакимият һәм халык депутатларының район Советы президиумы Мактау кәгазьләрен тапшырды.

***

Кичә сәүдә, көнкүреш хезмәте, торак - коммуналь хуҗалыгы көнен бәйрәм итү белән дәвам итте. Анда Ф.И.Гайнуллин һәм МПП начальнигы Э.К.Гайнуллин чыгыш ясадылар. Алдынгы эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең бер төркеменә шәһәр җирле үзидарәсе Советы Мактау кәгазьләре, кыйммәтле бүләкләр һәм акчалата премияләр тапшырылды. Соңыннан Татарстан һәм Башкортостанның атказанган артисты Фән Вәлиәхмәтов концерты булды.

**Т.НАЗАРОВА.**

## Юл газабыннан коткарды

Безнең Әмзә авылы районыбыздагы иң ерак төбәкләрнең берсе. Яңа Әмзә җирле үзидарәсенә кергән Иске Әмзә авылына Норлаттан 60, Яңа Әмзәгә 63, Чурабатырга 71, Кызыл Юл поселогына 75 километр. Ә кеше район үзәгенә нинди генә йомыш белән бармас.

Берничә еллап элек Норлат - Яңа Әмзә автобусы маршруты ачылгач, 4 авылның яше - карты юл газапларыннан котылуларыннан сөенгәннәр иде. Әмма... ике елдан бу арада хәрәкәт кискен начарайды: я килде автобус, я юк. Еш кына автобус маршрут азагына кадәр барып җитмичә, авыл кырыена чыккан халыкны калдырып, килерме - килмәсме дип икеләнеп, Әмзә юлы чатына чыгучыларны гына утыртып китә иде. Шулай итеп Норлатка ашыгыч йомыш белән баручылар, шулай ук Кызыл Юл, Чурабатыр кебек авыллардан күпме ара җәяү килүчеләр дә өйләренә кайтып китәргә мәҗбүр булалар иде. Озакламый «Норлат - Колбай Мораса» маршруты гына кала дип, безгә йөрүче автобусны да туктаттылар. Янә безнең өчен юл газабы башланды: барыбыз да (ә безнең арада карт - карчыклар, ветераннар, инвалидлар да бар иде) автобуска Мораса юлына чыга башладык. Өстәвенә «безбилетная система обслуживания» дип, шоферлар без, пенсионерлар, ветераннардан да юл хакы таләп итеп азаплый башладылар. Шундый намуссызлары очрады ки, алар хәтта автобусларын туктатып, карт - корыга кул күтәреп, җилкәдән сөйрәп төшерү белән дә яныйлар иде. Ә инде салонда йөри алмаслык кешеләр булганда «Хет Иске Әмзә авылы кырыена гына булса да илтә алмассызмы» дигән үтенечләрне колакларына да элмиләр иде. Дөрес, сирәк булса да араларында хәлебезгә керә торганнары да очрады. Боларның барысы хакында автовокзал начальнигына гына түгел, хакимияттә утыручы «зур абзыйларга»да гозер белән йөрдек. Әмма ач кайгысын тук белә мени...

Шөкер, районыбызга яңа җитәкче килгәч, ул беренче үтенечебез буенча ук катгый күрсәтмә бирде күрәмсең: якын көннәрдә үк «Норлат - Яңа Әмзә - Колбай Мораса» маршруты ачылды. Шатланып бетә алмыйбыз: хәзер ничә пассажир булуына карамастан иртәнге сәгать җиделәрдә, төштән соң дүртенче яртыда автобус Яңа Әмзә тукталышында була. Шоферларның да пассажирларга мөнәсәбәте үзгәрде. «Фатих Сәүбәновичка ихлас күңелдән зур рәхмәт», диләр безнең төбәктәге 4 авылның сугыш һәм хезмәт ветераннары, барча юл йөрүчеләр.

Без газета, җирле радио тапшырулары аркылы яңа җитәкчебез Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинның кыска вакыт эчендә башкарган күркәм эшләре турында укып, ишетеп торабыз. Бик хуп, районның элекке данын кайтарасы иде. Әле күптән түгел «Комбайн» КХАсында үткән гомуми җыелышта да әмзәлеләрнең барысы да 30 нчы мартта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны бердәм яклап тавыш бирәчәкләрен белдерделәр.

**Г.ҖАМАЛИЕВ.**
**Яңа Әмзә авылы.**

## Сатып алу бәяләре күтәрелде

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 6 мартта кабул иткән 213 номерлы карары нигезендә 1997 елның 1 мартыннан оешу - хокукый формалары төрле булган хуҗалыкларда эшкәртү промышленносте предприятиесе аша дәүләт ресурсларына сатыла торган терлекчелек продукциясен - терлек һәм сөтне сатып алу бәяләре күтәрелде.

**Һәр тонна өчен мең сумнарда**

| Продукция төре | Сатып алу бәясе | Дотация | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| **Тере үлчәүдәге терлек** | | | |
| **Мөгезле эре терлек һәм атлар** | | | |
| югары көрлектә | 2300 | 2300 | 4600 |
| уртача көрлектә | 1910 | 2150 | 4060 |
| уртачадан түбән көрлектә | 1440 | 1350 | 2790 |
| ябык | 1200 | 1120 | 2320 |
| **Югары авырлыктагы яшь мөгезле эре терлек 1 башның тереләй авырлыгы 401 - 450 кг.** | | | |
| югары көрлектә | 2880 | 2800 | 5680 |
| уртача көрлектә | 2390 | 2640 | 5030 |
| **Югары авырлыктагы яшь мөгезле эре терлек 1 башның тереләй авырлыгы 450 килодан артык** | | | |
| югары көрлектә | 3450 | 3350 | 6800 |
| уртача көрлектә | 2870 | 3130 | 6000 |
| **II һәм III категорияле дуңгызлар** | 4400 | 2700 | 7100 |
| IV категорияле | 4030 | 2480 | 6510 |
| стандарт булмаганнары | 2750 | 1700 | 4450 |
| **Сарыклар һәм кәҗәләр** | | | |
| югары көрлектә | 2700 | 3600 | 6300 |
| уртача көрлектә | 2150 | 3300 | 5450 |
| уртачадан түбән көрлектә | 1930 | 2200 | 4130 |
| ябык | 1000 | 1450 | 2450 |
| **Сөт** | | | |
| I сортлы | 800 | 290 | 1090 |
| II сортлы | 730 | 260 | 990 |
| сортсыз | 480 | 210 | 690 |
| **I сортлы сөт өсте (майлылыгы 10 проценттан да ким түгел)** | 3200 | - | 3200 |

Искәрмә:

а) кабул итү вакытында температурасы 10 градустан югары булмаган 1 сортлы сөт өчен һәр тоннасына 100 мең сум күләмендә өстәп түләнә;

б) кире кайтарып бирелә торган майсызландырылган сөтнең 1 тоннасы - 250 мең сум;

в) җитештерү өчен билгеләнгән югары сыйфатлы сөт:

балалар тукlануына билгеләнгән продуктлар өчен сатып алу бәясенә карата 50 процент күләмендә өстәп түләнә;

стерильләштерелгән продуктлар һәм сычужина (махсус матдәле) сырлары өчен сатып алу бәясенә карата 15 процент күләмендә өстәп түләнә;

г) атланмай һәм сарымай өчен килешү бәяләре буенча түләнә.

***Карарда күрсәтелгәнчә, эшкәртү промышленносте предприятиесе аша дәүләт ресурсларына сатыла торган продукция өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә дотация түләүне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, эшкәртү промышленносте предприятиеләренең статистик мәгълүматлары нигезендә, һәр айны, отчет аеннан соңгы айның 10нчы числосыннан да соңармыйча гамәлгә ашырырга бурычлы. Шул ук карарда: Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы терлекчелек комплекслары өчен бюджеттан катнаш азыкка бирелә торган дотацияне терлекчелек продукциясенә сатып алу бәяләрен дотацияләү өчен файдаланырга тиеш, дип күрсәтелә.***

### Безнең аңлатма

Хөкүмәтнең бу карарын республика хуҗалыкларында бик зарыгып көтеп алдылар. Чөнки авыл товар җитештерүчеләренең финанс хәле кризис чигенә килеп җиткән иде. Бүгенге көндә күп колхозларда һәм совхозларда эш хакы түләү 5 - 6 айга һәм аннан да озагракка тоткарлана. Кайбер хуҗалыкларда фермага салам ташый торган тракторлар өчен солярка сатып алырга да акча юк.

Авылларда яңа сатып алу бәяләрен ничек кабул итәләр соң? Хуҗалыкларның икътисадын савыктырырга китерерме алар?

Турысын әйтик, сатып алу бәяләренең яңа прейскуранты хуҗалык җитәкчеләрендә әлләни энтузиазм тудырмады кебек. Чөнки итнең сатып алу бәяләре һәр килограмм өчен уртача 800 - 900 сумга гына арта, анысы да әле дотацияне арттыру исәбенә генә. Ә бюджет дотацияләрен күчерү гадәттәгел тоткарлана.

Сөт бәясе дә күпкә күтәрелмәде.

Күрәсең, Хөкүмәт шәһәр кибетләрендә ваклап сату бәяләренең тотрыклы булуын саклау белән күбрәк кызыксынадыр. Бу аңлашыла да. Аннары бюджетның мөмкинлекләре дә бик чикле бит. Шулай да Хөкүмәтнең авыл товар җитештерүчеләренә финанс булышлыгы күрсәтү буенча чираттагы омтылышын хупларга кирәк.

(«Ватаным Татарстан»нан).

## Әле яшь кенә булса да...



Таныш булыгыз: шәһәрдә МПП карамагындагы йортларда санитария челтәре төзексезләнгән очракларда беренче ярдәмгә килүче егет слесарь - сантехник Сергей Петров. Коммуналь хуҗалыкта ул әле чагыштырмача яшь хезмәткәр, шуңа карамастан ул тиз арада тырышлыгы, эшен җиренә җиткереп үзвакытында башкаруы белән танылды. Шуңа күрә ул коллективта да хөрмәткә ия.


***«Девон - Кредит» акционерлык банкының хөрмәтле вкладчылары!***

**«Девон - Кредит» акционерлык банкы яңа кабул ителгән һәм срогы озайтылган кертемнәргә (вкладларга) 1997 елның 15 мартыннан яңа процент ставкалары куя.**

**Кертемнәрне кабул итү һәм саклау шартлары турында кирәкле консультация һәм мәгълүматларны сез «Девон - Кредит» акционерлык банкында ала аласыз.** Адрес: Норлат шәһәре, Совет ур., 179, тел.: 5 - 29 - 22 яки (коммутатор аша) 65 - 5 - 25, 65 - 2 - 27.

**Без сезнең белән очрашырга бик шатбыз.**
**«Девон - Кредит» АБ.**

**М**иллэт
**м**әгариф
**м**әдәният
**м**әгърифәт

# Телне кадерләгәч...

Мәктәпләрдә төрле фән атналыклары үткәрү традициядә. Күптән түгел шәһәрнең икенче рус - татар мәктәп - гимназиясендә узган татар теле һәм әдәбияты унконлеге дә балалар күңелендә матур тәэсир калдырды. Ул «Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр» дип аталды.

Ун көн буена мәктәп гөрләп торды. Бер генә көн дә кызыклы чарасыз үтмәде. «Сәнгатьле итеп шигырь сөйләүче», «Иң грамоталы укучы», «Яшь рәссам», «Татар җыры - 97» дип аталганнарында бөтен мәктәп катнашты дисәм, һич арттыру булмас. Аларның һәрберсендә телебез язмышы милләт язмышы дәрәҗәсенә күтәрелеп каралды. Бу әлеге унконлек рамкасында үткәрелгән һәр чарага да хас сыйфат иде. Мәшһүр сынчы Бакый Урманченың тууына 100, танылган язучы Галимҗан Ибраһимовның тууына 110 ел тулуга багышланган чаралар да балаларның халкыбыз тарихын ныграк үзләштерүләренә, яшь кешеләр күңелендә борынгыдан килә торган йолаларга, гореф - гадәтләргә мәхәббәт тәрбияләүдә нәтиҗә бирми калмас дип уйлыйм. Чараларның берсендә башкарылган «Бишек җыры» үзе генә дә ни тора иде. Әле кайчан гына шәһәребездә генә түгел, районда да балалар татар хоры юк иде. Ә менә биредә хор оештырылды. Аңа музыка мәктәбе укытучысы С.Х.Сафина җитәкчелек итә. Алда телгә алынган җырны да әлеге хор коллективы башкарды.

Гомумән, әлеге унконлек балаларның мәктәптән, дәрестән тыш вакытында аларны төрле кызыклы, файдалы шөгыльләр белән мавыктыру мөмкинлекләренең чиксез булуын тагын бер кат раслады. Рәсем түгәрәгенә йөрүче башлангыч сыйныф укучыларының рәсемнәре өлкән классларныкына караганда күпкә эчтәлеклерәк, төсләренең җанлырак булуын билгелисе килә. Фольклор түгәрәгенә йөрүче 3 нче «д» сыйныфы укучыларының да дәресләрдән соң тырышып шөгыльләнүләре бушка булмаган. Унконлек барышында алар «Кызыл калфак» әкиятен сәхнәгә куйдылар. Әлеге кичәгә килгән ата - аналар да балаларның чын артистларча уйнауларын сокланып күзәттеләр, нәни артистларның мәктәптә генә түгел, балалар бакчаларында да чыгыш ясауларын хупладылар.

Мәктәптә татар телен өйрәнүче рус балалары да унконлектә актив булдылар. Өченче сыйныфларның сәхнәдә саф татар телендә әкият уйнауларыннан һәркем канәгать калды.

Балаларның татар теленә карата мөнәсәбәте мәктәптә эшләүче татар теле укытучыларының балаларга ана теленә һәм әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләүдә актив алымнар кулланып эшләүләре нәтиҗәсе булуы сизелеп тора. Унконлек дәвамында барлык бәйгеләрдә актив катнашып призлы урыннарны яулаган 6 нчы «в» сыйныфы (җитәкчесе Н.Д.Һадыева) укучылары буенча да шундый нәтиҗә ясап була. Г.Ибраһимовның «Яз башы» әсәреннән бер өзекне сәхнәләштергән 5 нче сыйныф укучылары да ана телләренә булган мәхәббәтләрен тагын бер кат раслады.

Гомумән, унконлек нәтиҗәле һәм зур оешканлык белән үтте. Мәктәп җитәкчелеге дә мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эшен югары бәяләде. Март башында алар өчен махсус автобус белән Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына культпоход оештырылды.

**Ф.ЯКУПОВА.**

*ФИКЕР*

# Эш аты гына мени?

Узган елның декабрь аенда очраклы рәвештә Аксубай районы мәдәният йортында «Республикам минем Татарстан» дип аталган республика зона ярышларында катнашырга туры килде миңа. Анда безнең белән ызандаш алты районның үзешчән сәнгатькярләре катнашты.

Дөресен әйтим, Чистай районы вәкилләренең чыгышы күңелемдә аеруча зур тәэсир калдырды. Күзнең явын алырлык итеп киенгән япь - яшь татар кызлары һәм егетләре өздереп җырладылар, үкчәләреннән ут чыгарырлык итеп биеделәр. Алексеевск районы үзешчәннәре дә бик матур, килешле милли киемнәрдән чыгыш ясадылар.

Безнең районның музыка мәктәбе укытучыларының чыгышы да тамашачыларда җылы тәэсир калдырды. Әмма аларны караганда җан әрнеде: өсләренә кияргә рәтле - башлы татар милли киемнәре дә юк иде бит.

Үзем концерт карыйм, үзем уйланам. Күңелем белән алтмышынчы елларга кайттым. Ул чорда безнең районда үзешчән сәнгать югары дәрәҗәгә күтәрелгән иде. Безнең Югары һәм Түбән Норлат, Чишмә, Кормыш һәм Тарн - Варн авылларыннан торган «Дружба» күмәк хуҗалыгында рәис булып Шәриф Сәгыйрович Хафизов эшли иде ул вакытта. Нәкъ менә шул елларда мин үзем әлеге хуҗалыкның җыр һәм бию ансамбленә йөри идем. Көне буе эшләп, кич клубка җыела һәм кичләрне безне җырлап - биеп үткәрә идек. Анда инде тәртипсезләнү, эчү турында сүзнең чыгуы да мөмкин түгел. Ә Шәриф Сәгыйрович исә кырыкмаса - кырык төрле эшләрен ташлап, репетицияләрдә булырга өлгерә, безнең проблемаларыбызны кичектермичә хәл итә иде.

Ул елларда бер безнең хуҗалыкта гына түгел, тулаем район буенча да үзешчән сәнгать чәчәк атты. Димәк, үзешчәннәр «үз сокларында» гына кайнамаганнар, җитәкчелек тә аларны кайгырткан, ярдәменнән ташламаган.

Ә хәзер... Алда телгә алып үткән факт бүгенге көндә бездә мәдәният өлкәсенә мөнәсәбәтне ачык күрсәтә инде.

Авылларда үзешчән сәнгатьне торгызу буенча да бармакка бармак сугылмый дисәм дә дөрес булыр, мөгаен. Ә бит шул алда телгә алынган бәйгегә башка районнардан да авыл үзешчәннәре килгәннәр иде. Ә ни өчен әле безнең районнан да хәзерләп, алып бармаска иде. Дөресен әйтим; күп бит алар.

Сәхнә киемнәре турында аерым сөйлисем килә. Концертларга йөргәндә күзәткәнем бар: бер генә коллективның да сәхнәгә зәвыклы, заманча, милли киемнәрдән чыкканы юк диярлек. Чыкканнарының да өсләренә кигән киемнәре, кем әйтмешли, борынгы заманныкы, әйтерсең лә музей витринасыннан алынган. Чыгышлары да еш очракта алдан хәзерләнмәгән, йомшак була.

Гомумән, район мәдәният хезмәткәрләре булган талантларны да тиешенчә күрсәтә белмиләр, ахры. Соңгы елларда үзешчәннәребезнең чыгышларының телевидение буенча даими күрсәтелмәве дә кимсетә мине. Кемнән ким соң без? Без эш аты гына түгел, ә кешеләр дә: ипи генә түгел, рухи азыкка да мохтаҗлыгыбыз зур бит.

**М.МӨХӘММӘТГАЛИМ.**
**Норлат шәһәре.**

## Нәфис сүз осталары игътибарына

Халык арасында нәфис сүз сәнгатенең дәрәҗәсен күтәрү максатыннан быел Татарстан Мәдәният министрлыгы, Халык иҗаты һәм мәдәни - агарту эшләре буенча республика фәнни - методик үзәге халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай призына III республика бәйгесе үткәрә.

Бу бәйгенең тагын бер бик әһәмиятле максаты - профессиональ, үзешчән башкаручылар арасыннан яшь, талантлы нәфис сүз осталарын сайлап алу, халкыбызда сәнгатьнең бу төренә мәхәббәт уяту.

Районнарда конкурсның беренче этабы февраль - март айларында булса, 25 - 26 апрельдә Казанда икенче һәм өченче туры үткәреләчәк. Җиңүчеләр билгеле булгач, йомгаклау концерты да Казанда 26 апрельдә уздырылачак.

Бәйгедә катнашырга теләүчеләр түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итә алалар. **Казан шәһәре, Бауман урамы, 60 нчы йорт. Халык иҗаты һәм мәдәни - агарту эшләре буенча республика фәнни - методик үзәге. Телефон: 32 - 46 - 37.**

# «Гармун алып бирик, дуслар...»



Ул сәхнәгә чыгып, дәртле җырын сузып җибәрүгә, залдагы кешеләр җыр кодрәтенә буйсынып, бер сулыш, бер хис белән яши башлыйлар. Фирдүс моңлана - тыңлаучылар күзен дә сагыш баса, Фирдүс дәртле, шаян җыр суза - тамашачы күңеленә дә шатлык, яктылык иңә. Фирдүс моңына буйсынып, күңел түрендә иң яшерен саклаган хыял - өметләре җылысын татый, язмыш ачысын тойган җаннар дәва, шифа ала... Ә Фирдүс җырлый да җырлый. Кеп - кечкенә, гармунчы утыргычы артыннан аз гына башы күренгән чакта ук ул мәктәп, авыл сәхнәсенә чыкты, сабантуй мәйданнарын әсир итте, инде менә район мәдәният йортында зур мәртәбәле чараларда да ул - тансык, кадерле кунак. Тәмаевлар нәселендә җырлап үскән агалары, әтисе Фәрит сәләтен ходай аңа да кызганмыйча, мулдан биргән: җырны өздереп башкару өстенә, аңа килешле хәрәкәте, мимикасын таба белә, өлкәннәр сәхнә культурасы дип исемләгән бу катлаулы нәрсәдә дә үзен табигый, иркен тота. Шуңа тамашачы белән дә контактка тиз керә, аның мәхәббәтен тиз яулый Фирдүс. Ул Тәмаевлар гаиләсендә уртанчы бала, хәзер 8 нче класста укый. Һәр яңа җырны шунда ук өйрәнеп, тизрәк тамашачыга җиткерергә тырыша. Кем белә, бәлки тиздән энесе дә аның кебек үк җыры - моңы белән кешеләрне шатландырыр, исеме биграк өметле - Фирзәр бит! Ә бүгенгә әле Фирдүснең күңелендә яшереп йөрткән бер хыялы бар: гармунда уйнарга өйрәнәсе килә. Әтисенең энесе Рафик агасы төсле. Үз моңына үзе бизәк эзләр, гармуны белән дә кешеләр күңеленә ял, сихәт бирер иде.

Районның яшь җырчысына гармун кирәк. Нәкъ җырдагыча итеп, «Гармун алып бирик, дуслар!» дисәк, бәлки, яшь талантның хыялына канат куярлык игелекне башкаручы табылыр?

**С.НУРУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: Түбән Норлат авылыннан яшь җырчы Фирдүс Тәмаев район мәдәният йорты сәхнәсендә.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Гаилә белән сәхнәдә

Ул көнне Чулпан авылы мәдәният йортында залда буш урын табармын дип уйларга да юк иде. Үзешчәннәр концертын карарга халык шулай күп килде. Һәм үкенмәделәр дә, чөнки үзешчән артистлар (ә аларны санап чыгу да озакка китәр иде) моңлы һәм ягымлы матур тавышлары белән залны әсир иттеләр. Шулай да Әндәрҗановлар гаиләсен аерым әйтми мөмкин түгел. Алар менә ничә еллар инде үзләренең матур тавышлары һәм биюләре белән халыкка хезмәт күрсәтәләр. Бу юлы да Гөлүсә матур итеп җырлады, Гөлназ дус кызы Гүзәлия Хәлимова белән бик матур биеде, ә әниләре Флера концертны алып барды. Концертта нәфис сүз осталары да бик әйбәт чыгыш ясадылар. Алар үзләренең шигырьләре һәм скетчлары белән халыкка бик ошадылар. Менә шулай үзешчән артистлар ике сәгать буе халыкны бик әйбәт итеп ял иттерделәр һәм зал аларны алкышларга күмде.

**Р.ХӘЛИМОВА.**
**Чулпан авылы.**

